Personalia

# THE FIRST TATAR PROFESSOR IBRAHIM KHALFIN

**Fanuza Shakyrovna Nurieva,**
Kazan Federal University,
2 Tatarstan Str., Kazan, 420021, Russia,
fanuzanurieva@yandex.ru



**KHALFIN IBRAHIM ISHAKOVICH** – (1778-1829), was a teacher, an educator, and the first Tatar adjunct professor (1823). He taught the Tatar language at the first Kazan gymnasium for boys (1800-1829) and at Kazan University (since 1812).

His well-known works are devoted to teaching the Tatar hornbook, Tatar grammar, and the history of the Turkic peoples.

**ХӘЛФИН ИБРАҺИМ ИСХАК улы** (1778-1829) − педагог, мәгърифәтче, татарлардан беренче адъюнкт-профессор (1823), Исхак Хәлфиннең улы. Казандагы Беренче ир балалар гимназиясендә (1800-1829) һәм бер үк вакытта (1812 елдан) Казан университетында татар теле укыта.

Хезмәтләре татар теле әлифбасын һәм грамматикасын укытуга, төрки халыклар тарихына карый.

**ХАЛЬФИН ИБРАГИМ ИСХАКОВИЧ** (1778-1829) − педагог, просветитель, первый адъюнкт-профессор (1823) из татар, сын Исхака Хальфина. Преподавал татарский язык в Первой Казанской мужской гимназии (1800-1829) и одновременно (с 1812 года) в Казанском университете.

Труды по преподаванию татарской азбуки и грамматики, истории тюркских народов.

We have just celebrated the 235th Birthday of Ibrahim Khalfin, the first professor in the field of Tatar philology, who taught in the Department of Oriental Studies at Kazan University. This outstanding researcher's activities cannot be studied apart from the history of the Khalfin family. The Khalfin family played a key role in the history of the Tatar enlightenment and the history of social consciousness, as they were many things: statesmen, interpreters, teachers, lexicographers, scientists, religious figures, businessmen, and merchants. The founder of Tatar language methodology, Sagit Khalfin, and his successors Iskhaq, Ibrahim, Ismagil, and Shakhingarai taught the Tatar and other Oriental languages at the gymnasium and university in Kazan for more than sixty years.

I.Khalfin was born in 1778 in the old Tatar district of Kazan, at the same time as his grandfather was finishing the first Tatar hornbook. Sagit Khalfin was an outstanding Turkologist, a founder of Tatar linguistics. By the edict of Catherine II, the Tatar language was to be taught at the First Gymnasium in Kazan with the aim of training interpreters. Having knowledge of the Tatar, Arabic and Persian languages, the interpreter Sagit Khalfin was appointed a teacher. For 16 years (1769 − 1785) Sagit Khalfin taught at the gymnasium. In the absence of textbooks, the teacher produced his own study guides, revising them periodically throughout his life. His first secular hornbook of the Tatar language, "The Tatar language ABC-book" was published by Moscow University Publishing House ("The Tatar language ABC with a Detailed Description of the Letters and Syllables, Written by Sagitl Khalfin, a Kazan Gymnasium Teacher and Admiralty Offices Interpreter, Analyzed and Approved by the Mullahs of Kazan Tatar Districts"). He also completed a Russian-Tatar dictionary with a list of 23,000 words in manuscript form. According to the requirements of that time, this bilingual dictionary listed words alphabetically in two languages, revealing the richness of the Tatar language. Indo-European language researcher, Otto von Böhtlingk, used this dictionary in writing his treatise about the Yakut language.

Sagit Khalfin is known as a translator of Pugachev's works as well as official Russian government documents. His son, Ishaq Khalfin, replaced his father in the First Gymnasium, teaching the Tatar language from 1785 to 1800, translating government acts into Tatar. For this work, he was appointed a province secretary. At that time, the Tatar language was an international language of communication, thanks to the efforts of Khalfin.

Ibrahim Khalfin followed the trails of his grandfather and his father and devoted his life and his knowledge to research into the national language and national history and to serving his nation.

In 1800, after the death of his father, Ishaq Khalfin began to teach Tatar at the First Gymnasium for boys. He knew the Tatar, Russian, Turkish, Arabic, Persian and Latin languages perfectly. Ibrahim Khalfi reached new heights of science, and the example of his grandfather's book helped him to organize his work in a systematic way. He did his best at learning and teaching the Tatar language. The Gymnasium aimed to have experienced interpreters who were fluent in foreign languages. Alongside the Tatar language, they taught such other Near-Eastern languages as Turkish and Arabian. As the polyglot classes were interesting both for learning and research, the number of students, who wanted to attend these lessons, kept growing. Ibrahim Khalfin used Russian texts to develop the skills of his students in translation and taught Comparative Tatar-Turkish Language classes four days a week. As a result, he was nominated for an award for his great work.

The outstanding researcher, Ibrahim Khalfin, published his new book "The ABC-Book and Etymology of the Tatar Language", where he described new methods of teaching language. The book was published by the Asia Printing House in a large circulation (1200 copies) and it became the main Tatar language course book in Russian cities. Russian, Tatar, Bashkir, Kalmyk and Mongol children used it in the classroom.

Ibrahim Khalfin's book "The Tatar language Alphabet and Grammar with Rules for the Reading of Arabic, Taught at the Imperial Kazan Gymnasium" was known not only among the scientist in Russia, but was familiar to Western scientists. The part of the book on grammar was excellent, presenting new scientific approaches to studying Tatar. The work consisted of two parts. The first part was devoted to orthography and phonetics, the alphabet and writing basics, vowels and consonants, vocalic harmony and other phonetic issues (62 pages). The second part dealt with parts of speech and grammatical categories (106 pages). The dominant norms of Tatar literary language in the 18th century began to approximate the spoken language. For a long time, the book served as a textbook, an example to follow in further research and study.

In 1812, the Tatar language began to be taught at Kazan University and Ibrahim Khalfin was employed as a Tatar language teacher there. As he worked at both the gymnasium and university, his scientific and pedagogical activity kept expanding. He established contacts with outstanding Russian and foreign scientists. University scientists then considered that the main aim of linguistics was to study the spiritual life and history of the nation alongside structural language studies. Another aspect of language studies for Kazan Turkologists was to use comparative and historical methods in their research. These ideas had great influence on Ibrahim Khalfin and his scientific activity. He dedicated his research and his life to studying the history of the Tatar nation, educating Tatars, and developing ethnic self-awareness. Being interested in the historical background of all the classes in the ethnic society, he started publishing ancient literary documents and historical manuscripts.

Ibrahim Khalfin found and prepared for publishing such books as "*Dastane Chyngyz khan ve Aksal Timer"* (1819) and *"Khiva khani Abelgaziy Bahadur khan "Shazhara-el-Turk"* (1820). Additionally, in 1818, he wrote a book about Kazan provincial geography in manuscript form. Ibrahim Khalfin and the German scientist K. M. Fren, studied the Golden Horde's Decree of *Timer Koliq* and published it in Latin in the "Fundgruben des Orients," journal in Vienna. His next book, "Dactane Genghis Khan ve Aksaq Timer," was published by English Turkologist, Arthur Lumley Davids' in London ten years later. The German scientist Zenker included parts of the material from this book in his work. Eventually, the book came to Eastern Europe, where it was discussed by the academic community. Ibrahim Khalfin also translated parts of the book, *"Shazhara et-Turk"* into Russian and sent these sections to St.Petersburg, where it attracted the attention of scientists.

During the period of 1802 − 1828, Ibrahim Khalfin worked for the Asia Publishing House at the gymnasium. He censored Tatar, Arabian and Turkish books in literature, religion, history and science. Working for the publishing house, he tried to preserve the works' cultural heritage and disseminate knowledge in these works throughout the nation. He aimed to publish various appeals and announcements, where he made entreaties for preserving the national language, for the study of national history and invited people to meetings held in the gymnasium and at the university. In addition, he continued to collect and preserve Tatar-Turk, Arabian and Persian manuscripts at the university library. Owing to his care and effort, a number of ancient manuscripts were saved from destruction.

Ibrahim Khalfin was a teacher and a scientist, who used new methods in teaching and inspired with new ideas and thoughts. He left his mark in history. In 1822, he sent a handwritten copy of his lectures on the Tatar language for students in the Arabian-Persian department of the university's governing body. His scientific and methodological manuscript "Synopsis of the Tatar Language" is kept in the Kazan University library and the central state archives of Tatarstan. It contains ideas about the history of the Turkic people and the state of the Tatar language in the 19th century. Ibrahim Khalfin pointed out the importance of the relationship between language and history in learning a language and studied Tatar language evolution from ancient times, employing historical-comparative method. We regret to state that Ibrahim Khalfin's historical-comparative method of study and theory of the Tatar language have not hitherto received adequate recognition. Being an outstanding scientist, Ibrahim Khalfin became the founder of Tatar linguistics as a science and in 1823, he became the first Tatar adjunct professor.

Ibrahim Khalfin was famous for his many works. He was not only a well-known scientist, however, but a large-minded public figure who supported the enlightenment process, trying to involve Tatar department students in public outreach. Consequently, he sent a project to the University Academic Council on the necessity of opening national schools with secular education.

Despite working long hours, he lived modestly, almost in a hand to mouth fashion, a very modest, self-denying person. He liked his job and fostered respect for the profession of teacher. A year before his death, his son Shakingarai Khalfin entered Kazan University and after graduating from the university he taught the Tatar language at the gymnasium.

Ibrahim Khalfin died of a heart attack at the age of 51 while teaching class. His relatives, friends, colleagues, students and even N.I.Lobachevski, the rector of Kazan University came to his funeral. According to the University Academic Council's decision, his family received a pension on behalf of Khalfin.

The outstanding scientist, teacher, educator and public figure, Ibrahim Khalfin left us a great legacy. His activity and hard work in the linguistic and educational spheres have not disappeared, on the contrary, they have a great impact on contem-

porary linguistic research and modern Tatar scientists base their studies on his works.

There are a number of scientists and writers who have studied Khalfin's family legacy and brought it to light through their own works (J.Validi, G.Gubaidullin, M.Gali, M.Nogman, A.N.Kononov, S.M.Mikhailova, V.G.Gosmanov, S.S.Khanbikova, V.K.Khakov, F.S.Safiullina, R.M.Valeev, D.Garifullin, S.Grigoriva, F.Bairamova, and L.Devyatykh, etc.) While writing this article, dedicated to this outstanding Tatar person's birthday, we consulted archival material on the Khalfin family and works of the above mentioned scientists and writers.

The Khalfin family tree has been of great interest for researchers in recent years. Studies of different historical periods reveal the ways generations of the Khalfins worked for enlightenment and education, devoting their lives to the national cause.

**References**


1. *Välidi Ž.* Khälfinnär // Shura. 1913. №3-5 (in Arabic font). (in Tatar).
2. Bibliograficheskiy slovar' otechestvennykh tyurkologov. M.: Nauka, 1974. 342 s. (in Russian).
3. *Akhmetgaleeva Ya.S.* Grammatika tatarskogo yazyka Ibragima Khal'fina // Sovetskaya tyurkologiya, 1979. №6. S. 23-30. (in Russian).
4. *Valeev R.M.* Soobrazhayas' s obrazom mysley nashey natsii // Ekho vekov. 1997. №1-2. S. 54-61. (in Russian).
5. Kazanskaya lingvisticheskaya shkola: Kniga pervaya: Kazanskaya tyurkskaya lingvisticheskaya shkola / sost. M.Z.Zakiev. Kazan': Tatar. kn. izd-vo, 2008. 424 s. (in Russian).
6. *Mikhaylova S.M.* Ibragim Iskhakovich Khal'fin. Kazan': Izd-vo Kazanskogo un-ta, 2002. 40 s. (in Russian).
7. *Yarullina L.* Khälfinnar – berenche tatar älifbasyna nigez saluchylar // Fän häm tel. 2008. №2. 29-31 b. (in Tatar).


# БЕРЕНЧЕ ТАТАР ПРОФЕССОРЫ ИБРАҺИМ ХӘЛФИН


**Фәнүзә Шәкүр кызы Нуриева**,
Казан федераль университеты,
Россия, 420021, Казан ш., Татарстан ур., 2 нче йорт,
fanuzanurieva@yandex.ru


Казан университетының Көнчыгыш бүлегендә укыткан, татар тел белеме өлкәсендә иң беренче профессор дәрәҗәсенә лаек булган Ибраһим Хәлфиннең тууына 235 ел. Олуг галимнең эшчәнлеген татар мәгърифәтчелеге һәм иҗтимагый фикере тарихында тирән эз калдырган Хәлфиннәр нәселеннән аерып өйрәнү мөмкин түгел. Алар арасында йомышлы татарлар, дәүләт эшлеклесе, тәрҗемәче, укытучы, лексикограф, галим, дин эшлеклесе һәм сәүдәгәрләр бар. Бөтен гомерләрен туган халкына хезмәт итүгә багышлаган шушы зыялы нәселдән чыккан Ибраһим Хәлфин дөньякүләм билгеле галим булып танылган. Татар телен өйрәнүгә һәм өйрәтүгә нигез салган Сәгыйть Хәлфин һәм аның варислары Исхак, Ибраһим, Исмәгыйль, Шаһингәрәй алтмыш елдан артык гимназиядә һәм университетта татар теле һәм көнчыгыш телләр укытканнар.

Ибраһим 1778 елда Казанның Иске Татар бистәсендә, Сәгыйть бабасы беренче татар әлифбасын тәмамлап килгән мәлдә Исхак Хәлфин гаиләсендә дөньяга килә. Тюркология фәнендә Сәгыйть Хәсән улы татар тел белеменә нигез салган шәхес буларак бәяләнә. 1769 елда Екатерина II указы белән Казанда Беренче гимназиядә, тәрҗемәчеләр әзерләү максаты белән, татар теле укытыла башлый. Укытучы итеп татар, рус, гарәп һәм фарсы телләрен яхшы белгән тәрҗемәче Сәгыйть Хәлфин билгеләнә. Ул уналты ел (1769−1785) гимназиядә укыткан, дәреслекләр, кулланмалар булмаганлыктан, аларны башлап үзе төзегән, эш барышында камилләштергән. Башта 52 биттән торган «Татар теленең әлифбасы...» («Азбука татарского языка с обстоятельным описанием букв и складов, сочиненная Казанских гимназий учителем и Адмиралтейской конторы переводчиком Сагитом Хальфином, в татарских в Казани слобод муллами в оных гимназиях рассмотренная и одобренная») хезмәтен язып, 1778 елда Мәскәү университеты типографиясендә бастырып чыгара. Шулай ук 23 мең чамасы сүзне теркәгән ике томлы русча-татарча сүзлек төзи. Телебезнең байлыгын

үзенә җыйган, алфавит тәртибендә бирелгән бу сүзлек төзелеш принцибы белән шул чор таләпләренә җавап бирерлек итеп эшләнгән. Мисал өчен, якут теленнән хезмәт язганда, һинд-европа телләре белгече О.Н.Бетлинг әлеге сүзлектән файдалана.

Сәгыйть Хәлфин Пугачев документларын, Россия хөкүмәтенең эш кәгазьләрен тәрҗемә итүче шәхес буларак та билгеле. Улы Исхак Хәлфин этисе эшен дәвам итә, 1785 елдан алып 1800 елга кадәр шул ук гимназиядә татар телен укыта, күп кенә дәүләт актларын татарчага тәрҗемә итә, хезмәтләре өчен губерна сәркатибе итеп билгеләнә. Ул чакта татар теленең күп кенә дәүләтләр белән халыкара аралашу теле булуын искә алсак, Хәлфиннәр эшчәнлегенең әһәмияте тагын да калкурак күренә.

Ибраһим Хәлфин дә бабасы һәм этисе юлыннан китә, үзенең бөтен гомерен, белемен халкының телен, тарихын өйрәнүгә, аның мәнфәгатьләренә хезмәт итүгә багышлый. 1800 елда этисенең вафатыннан соң шул ук Беренче ирләр гимназиясендә татар теле укыта башлый. Хәзерлекле, татар, рус, төрек, гарәп, фарсы, латин телләрен камил үзләштергән Ибраһим Хәлфин якыннарының эшен дәвам итеп кенә калмый, яңа биеклеккә күтәрә. Әлбәттә, буыннар аша килгән тәҗрибә, бабасының дәреслеге укыту эшчәнлеген уңышлы оештыруга ярдәм итә. Хәлфин үзе дә татар телен укытуга бәйле уңай үзгәрешләр кертүгә ирешә. Телләрне камил белүче тәрҗемәчеләр әзерләү максаты белән гимназиядә көнчыгыш телләрне өйрәнүгә игътибар арта, татар теле белән беррәттән төрек һәм гарәп телләре укытыла башлый. Берничә тел белгән галим дәресләрен югары фәнни дәрәҗәдә, кызыклы итеп үткәрә, дәресләренә йөрүчеләрнең саны арту моның ачык дәлиле. Укучыларына тәрҗемә күнекмәләре бирү өчен, ул русча текстларны куллана, татар теленең үзенчәлекләрен төрек теле белән чагыштырып өйрәнә. Ибраһим Хәлфин зур тырышлык куеп, татар теле дәресләренең атнага дүрт тапкыр укытылуына ирешә. Гимназия җитәкчелеге тырыш хезмәте өчен аны бүләкләүгә тәкъдим итә.

Эзләнүчән галим тел фәнен укытудагы яңа методларны файдаланып, 1804 елда «Татар теленең әлифбасы һәм этимологиясе» («Азбука и этимология татарского языка») дәреслеген төзи. Әлеге хезмәт шул вакыт өчен күрелмәгән зур тираж белән (1200 данә) гимназия бинасында урнашкан Азия басмаханәсендә нәшер ителә һәм бик озак вакытлар Россия шәһәрләрендә татар сыйныфлары өчен төп дәреслек булып тора. Аннан рус, татар, башкорт, калмык, монгол балалары да белем ала.

Ибраһим Хәлфиннең «Азбука и грамматика татарского языка с правилами арабского чтения, преподаваемые в Императорской Казанской гимназии» («Казан гимназиясендә укытыла торган татар теле әлифбасы һәм грамматикасы, гарәби укылыш кагыйдәләре белән», 1809) хезмәте Россиядә генә түгел, Көнбатыш Европа илләре галимнәре арасында да билгеле була. Әлеге дәреслек үзенең тулылыгы белән моңа кадәр чыккан грамматикалардан аерылып тора, татар телен фәнни өйрәнү юнәлешендә мөһим адым була. Хезмәт ике бүлектән тора. Графика һәм фонетика бүлегендә (62 бит) әлифба һәм язу мәсьәләләренә, сузык һәм тартык авазларга, сингармонизм закончалыгына һ.б. фонетик күренешләргә игътибар ителә. Икенче бүлектә (106 бит) сүз төркемнәре һәм аларга хас грамматик категорияләр тикшерелә. Грамматикада татар әдәби теленең XVIII гасырдагы төп нормалары чагылыш тапкан, әдәби нормаларның халык сөйләм теленә нигезләнә башлавы күрсәтелгән. Бу хезмәт озак вакытлар бердәнбер уку китабы булган, алдагы буын телчеләр өчен үрнәк булып торган.

1812 елда Казан университетында татар теле укытыла башлый, укытучы итеп Ибраһим Хәлфин чакырыла. Гимназия белән бергә университетта да эшли башлагач, ул үзенең гыйльми һәм педагогик эшчәнлеген тагын да киңрәк җәелдерә. Атаклы рус һәм чит ил галимнәре, профессорлары белән аралаша башлый. Университет галимнәре лингвистиканың төп бурычын аерым бер телнең төзелеш структурасын тикшерүдә генә түгел, шул телдә сөйләшүче халыкларның рухи тормышын, тарихын тикшерүдә дә күргәннәр. Тагын шунысы әһәмиятле: Казан тюркологлары телләрне чагыштырма-тарихи ысул белән өйрәнүне алгы планга куйганнар, телләрнең тигез хокуклы, фән өчен бердәй әһәмиятле дигән караштан чыгып эш иткәннәр. Университет галимнәренең фикерләре Ибраһим Хәлфиннең эшчәнлегенә, фәнни карашларына да йогынты ясамый калмаган. Галим үзенең күпьеллык фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеген туган халкының тарихын өйрәнүгә, татарларны мәгърифәтле итүгә, милли үзаң тәрбияләүгә багышлый. Халыкның төрле катлауларында

тарихи үткәнебез белән җитди кызыксыну теләге уяту максатында, борынгы әдәби, тарихи ядкәрләрне бастырып чыгару эшен башлап җибәрә.

Галим үзе тапкан, матбугатка әзерләгән «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» (1819), Хива ханы Әбелгазый Баһадур ханның «Шәҗәрә әт-төрк» (1820) китаплары төрки-татар тарихи чыганакларын нәшер итүнең башлангычы булып тора. Болардан тыш, галимнең Казан губернасы географиясе хакында 1818 елда язган китабы кулъязма килеш кала. Алман галиме, академик Х.М.Френ белән бергә Алтын Урда дәүләте чорында язылган Тимер Котлыг тархан ярлыгын тикшереп, Вена шәһәрендә «Fundgruben des Orients» журналында латин телендә бастыралар. «Дастане Чыңгыз хан вә Аксак Тимер» ун елдан соң Англия тюркологы Артур Давидс тарафыннан Лондонда кабат бастырыла, алман галиме Ценкер дә аны үз хезмәтенә кертә. Шулай итеп, бу мөһим чыганак Көнбатыш Европага барып ирешә, фәнни бәхәсләр кузгата. Ибраһим Хәлфин, «Шәҗәрә әт-төрк»нең аерым бүлекләрен русчага тәрҗемә итеп, Петербургка җибәрә, әлеге әсәр дә төрле ил галимнәренең игътибарын җәлеп итә.

Ибраһим Хәлфиннең бу фидакяр эшчәнлеге, беренче чиратта, Казан гимназиясе каршында ачылган басмаханәгә бәйле, чөнки 1802 елдан алып 1828 елга кадәр аның цензоры булып эшли. Шул типографиядә татар, гарәп, төрек телләрендә басылган әдәби, дини, тарихи, фәнни китапларның барысы диярлек аның кулы аша уза. Галим Азия басмаханәсен халкыбызның мәдәни мирасын саклап калу, халыкка тарату өчен файдаланырга тырыша. Аның тарафыннан типографиядә бастырылган күпсанлы мөрәҗәгать һәм игъланнар шул турыда сөйли. Хәлфин татарларны үз телләрен һәм тарихларын өйрәнергә, белем алырга өнди, гимназиядә һәм университетта уздырыла торган очрашуларга, кичәләргә чакыра. Моннан тыш, университет китапханәсенә төрки-татар, гарәп һәм фарсы кулъязмаларын туплау юнәлешендә зур эш башкара. Аның тырышлыгы белән йөзләгән борынгы кулъязма университет китапханәсенә алынып, эзсез югалудан коткарып калына.

Ибраһим Хәлфин − гыйльми һәм укыту эшчәнлегендә яңа методлар кулланып, татар теленең киләчәк үсешенә яңа эз салган галим. 1822 елда ул татар теленнән гарәп-фарсы кафедрасы студентларына укыячак лекцияләренең конспектын үз кулы белән язып, университет җитәкчелегенә җибәрә. Аның «Конспект татарского языка» («Татар теленең конспекты») дигән кулъязма фәнни-методик эшкәртмәсе әле дә Казан университеты китапханәсендә һәм Татарстанның Үзәк дәүләт архивында саклана. Анда төрки телләр тарихына бәйләнешле һәм татар теленең XIX гасыр башындагы тел торышы турында кыйммәтле фикерләр бар. Конспектта Хәлфин тел дәресләрен тарих белән бәйләнештә алып баруга зур игътибар бирә. Ул халыкның теле белән тарихы табигый рәвештә бәйләнгән дип санап, борынгы чордан башлап татар теленең формалашу һәм үсү юлларын чагыштырма-тарихи караш нигезендә өйрәнергә омтыла. Ибраһим Хәлфиннең бу юнәлештәге башлангычы, татар теле теориясен нигезләүдәге роле хәзергәчә тулысынча ачыкланмаган. Билгеләп үтелгәнчә, ул татар тел белеменең гадәти вәкиле генә түгел, үзенең киңкырлы фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән татар теле фәнен тудырган галим. Фән һәм мәгариф өлкәсендәге уңышлары өчен Ибраһим Хәлфин 1823 елда татарлардан беренче булып адъюнкт-профессор дәрәҗәсенә лаек була.

Галим үзенең хезмәтләре белән дан казана. Әмма Ибраһим Хәлфин «коеп куйган галим» генә түгел. Киң карашлы галим мәгърифәтчелек хәрәкәтенең алгы сафында була. Университетта татар теле өйрәнүче студентларны халык арасында мәгърифәтчелек эше алып баруга җәлеп итәргә кирәк дип саный. Аның татарлар арасында дөньяви белемнәр таратуга һәм милли мәктәпләр ачу мәсьәләсенә карата университет Советына язып биргән проектлары бар.

Гомере буе киеренке эштән аерылмаса да, хезмәт хакы очын-очка ялгап барырлык кына була. Галим һәм укытучы Ибраһим Хәлфин гаҗәп тыйнак һәм мәрхәмәтле кеше була, шәхси мәнфәгатьләрен алга куймый, үз эшен яратып башкара, балаларында да укытучы һөнәренә хөрмәт тәрбияли. Вафатына бер ел кала улы Шаһингәрәй Хәлфин Казан университетына укырга керә, укуын тәмамлагач, гимназиядә татар теле укытуны дәвам итә. Ибраһим Хәлфин 1829 елның гыйнварында, 51 яшендә, дәрес вакытында, йөрәк авыруыннан кинәт вафат була. Татар халкының галим улын соңгы юлга озатуда якыннары, дуслары, хезмәттәшләре, студентлар белән бергә университет ректоры профессор

Н.И.Лобачевский дә катнаша. Университет Советы карары белән аның гаиләсе пенсия белән тәэмин ителә.

Күренекле галим, педагог, мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе Ибраһим Хәлфин үзеннән соң бай мирас калдыра. Аның күпьеллык эшчәнлеге эзсез югалмый, бүген дә татар теле өлкәсендә эшләүче галимнәр кыйммәтле фәнни чыганак буларак хезмәтләренә таяналар, иҗатына югары бәя бирәләр. Хәлфиннәр династиясенең эшчәнлеген өйрәнгән, архивларда сакланган материаларны халыкка җиткерүдә зур эш башкарган хөрмәтле галимнәр, язучылар Җ.Вәлиди, Г.Гобәйдуллин М.Гали, М.Ногман, А.Н.Кононов, С.М.Михайлова, М.Г.Госманов, Ш.С.Ханбикова, В.Х.Хаков, Ф.С.Сафиуллина, Р.М.Вәлиев, Д.Гарифуллин, С.Григорьева, Ф.Бәйрамова, Л.Девятых һ.б. хезмәтләрен ихтирам белән атап үтү мәслихәт булыр. Без дә Ибраһим Хәлфиннең юбилее хөрмәтенә язылган мәкаләбездә галимнең архивларда сакланган материалларга, исемнәре телгә алынган авторларның хезмәтләренә нигезләндек.

Соңгы елларда данлы, зыялы Хәлфиннәр нәселенең шәҗәрәсен өйрәнү эше җанланып китте. Тарихи чорлар бүленешендә аларның буыннан-буынга татар халкының мәгърифәте, милләт киләчәге турында кайгыртып яшәве, тормышын җиңеләйтү өчен кылган изге гамәлләре тагын да ачык күренә.

**Әдәбият**

1. *Вәлиди Җ.* Хәлфиннәр // Шура. 1913. №3-5 (гарәп шрифтында).
2. Библиографический словарь отечественных тюркологов. М.: Наука, 1974. 342 с.
3. *Ахметгалеева Я.С.* Грамматика татарского языка Ибрагима Хальфина // Советская тюркология, 1979. №6. С. 23-30.
4. *Валеев Р.М.* Соображаясь с образом мыслей нашей нации // Эхо веков. 1997. №1-2. С. 54-61.
5. Казанская лингвистическая школа: Книга первая: Казанская тюркская лингвистическая школа / сост. М.З. Закиев. Казань: Татар. кн. изд-во, 2008. 424 с.
6. *Михайлова С.М.* Ибрагим Исхакович Хальфин. Казань: Изд-во Казанского ун-та, 2002. 40 с.
7. *Яруллина Л.* Хәлфиннар – беренче татар әлифбасына нигез салучылар // Фән һәм тел. 2008. №2. 29-31 б.